РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«10» октябрь 2022г.

с. Тюлячи

№ 197

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 24 декабрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 6 сентябрендәге 826 номерлы "Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программал ары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында" карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2021 елның 7 сентябрендәге 842 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 24 декабрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» карарына (08.02.2016 № 41, 29.01.2017 № 34, 20 июнь 2017 № 328, 29.12.2018 № 879, 16.11.2020 № 498, 31.12.2020 № 620, 15.02.2021 № 55, 19.03.2021 № 124, 29.12.2021 № 325 карарлар редакциясендә) түбәндәге эчтәлекле 1.2.5 пунктчасы белән тулыландырып, үзгәреш кертергә: «1.2.5. 2022 елның 10 октябреннән 2022 елның 31 декабренә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән укучыларны һәр уку көненә 8 сум 30 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-ана түләвеннән торган бушлай кайнар ризык белән тәэмин итәргә. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләвен җирле бюджет акчалары исәбеннән түләргә».

2. МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» нә (Карпова Н.В.), хәрби комиссариатның мәгариф оешмасында тәрбияләнүченең гаилә әгъзасын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру турындагы белешмәсе нигезендә, 1 пунктта китерелгән ташламаны күрсәтергә.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин